КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 21 апрель г.Казань № 275

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен оештыру, үзгәртеп оештыру, аларның тибын үзгәртү һәм бетерү тәртибен билгеләү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючы һәм аларның мөлкәте милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен регламентлаштыру өлешендә Татарстан Республикасында «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең хокукый хәле камилләштерелүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 ел, 8 май, ФЗ-83 нче Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2010 ел, 18 октябрь, 820 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен оештыру, үзгәртеп оештыру, тибын үзгәртү һәм бетерү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре уставларын раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен оештыру, үзгәртеп оештыру, аларның тибын үзгәртү һәм бетерү тәртибен билгеләү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючы һәм аларның мөлкәте милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен регламентлаштыру өлешендә Татарстан Республикасында «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең хокукый хәле камилләштерелүгә бәйле рәвештә,

Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 ел, 8 май, ФЗ-83 нче Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2010 ел, 18 октябрь, 820 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 17 май, 388 нче; 2012 ел, 20 октябрь, 879 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләрен оештыру, үзгәртеп оештыру, тибын үзгәртү һәм бетерү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре уставларын раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

V бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 37.1 пункт өстәргә:

«37.1. Эшчәнлекнең аерым тармакларында (балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерүче, гражданнар сәламәтлеген саклау һәм мәгариф тармакларында) Татарстан Республикасы учреждениеләрен үзгәртеп оештыру һәм бетерү законнарда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин